ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 апрель, 2016 ел № 7/17

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар бирү турында, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар бирү турында нигезнамәне раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүне контрольдә тоту турында» 230-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге «Керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 460 санлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 22 апрелендәге «Татарстан Республикасының дәүләт вазифаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар бирү турында, Татарстан Республикасының дәүләт вазифаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар бирү турында» Татарстан Республикасы Перзиденты Указына үзгәрешләр кертү хакында» УП-330 санлы Указы, шәһәр Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар бирү турында, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар бирү турында нигезнамәне 1 кушымта нигезендә;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазифасын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларын шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны, бастырып чыгару өчен, массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен 2 кушымта нигезендә.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
7/17 нче Карарына 1 кушымта
7 апрель, 2016 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар бирү турында, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар бирү турында нигезнамә

1. Әлеге Нигезнамә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан алынган керемнәре хакында, милек хокукында ия булган мөлкәте хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар бирү, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре хакында, милек хокукында ия булган мөлкәте хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар (алга таба – керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар) бирү тәртибен билгели;

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүче затлар тарафыннан алынган керемнәре хакында, милек хокукында ия булган мөлкәте хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар бирү, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре хакында, милек хокукында ия булган мөлкәте хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар (алга таба – керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар) бирү тәртибен билгели.

2. Әлеге Нигезнамәдә каралган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүче затларга Шәһәр Советы депутатлары, Контроль-хисап палатасы рәисе керә.

3. Шәһәр Хакиме, муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе муниципаль вазифасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар (алга таба – муниципаль вазифа биләүне дәгъвалаучы гражданнар) тарафыннан керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге «Керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 460 санлы Указы (алга таба – Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 санлы Указы) белән расланган белешмә формасы буенча, вазифа буенча вәкаләтләр бирелгәндә (вазифага билгеләнгәндә, сайланганда) тапшырыла.

Шәһәр Советы депутатына кандидатлар керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларны 2002

елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары төп гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында» 67-ФЗ санлы Федераль законда каралган форма буенча законнарда каралган тәртиптә һәм срокларда тиешле сайлау комиссиясенә тапшыралар.

4. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 санлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленә кадәр ел саен тапшырыла.

5. Муниципаль вазифа биләүне дәгъвәлаучы гражданин, вазифа буенча вәкаләтләр алганда (вазифага билгеләнү, сайлану), түбәндәгеләрне тапшыра:

1) муниципаль вазифаны биләү өчен документлар тапшыру елыннан алда килгән календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган (элекке эш урыны яки сайлап куела торган вазифаны биләү урыны буенча керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) керемнәре турында мәгълүматларны, шулай ук муниципаль вазифаны биләүгә документлар тапшыру ае алдыннан килгән айның беренче числосы торышына (хисап датасына) милек хокукында ия булган мөлкәте хакында һәм үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматларны;

2) муниципаль вазифаны биләү өчен документлар тапшыру елыннан алда килгән календарь ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) керемнәре турында мәгълүматларны, шулай ук муниципаль вазифаны биләүгә документлар тапшыру ае алдыннан килгән айның беренче числосы торышына (хисап датасына) милек хокукында ия булган мөлкәте хакында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматларны;

6. Муниципаль вазифа биләүче зат ел саен түбәндәгеләрне тапшыра:

1) хисап чоры өчен (1 январьдән 31 декабрьне кертеп) барлык чыганаклардан алынган (акчалата түләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) керемнәре хакында мәгълүматларны, шулай ук хисап чоры ахырындагы торыш буенча милек хокукында ия булган мөлкәте хакында һәм үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматларны;

2) хисап чоры өчен (1 январьдән 31 декабрьне кертеп) хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган (акчалата түләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) керемнәре хакында мәгълүматларны, шулай ук хисап чоры ахырындагы торыш буенча милек хокукында ия булган мөлкәте хакында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматларны;

3) хисап чоры өчен (1 январьдән 31 декабрьне кертеп) җир кишәрлеген, башка күчемсез милек обектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кагәзьләр (оешмаларның устав капиталларындагы катнашу

өлеше, пайлары) сатып алуның һәр килешүе буенча үзенең чыгымнары хакында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында, әгәр мондый килешүләрнең суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) килешү төзер алдыннан килгән соңгы өч ел өчен гомуми кеременннән артып китсә, һәм бу килешүләрне башкаруга средстволар алу чыганаклары хакында мәгълүматларны.

7. Мәгълүматлар Керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту буенча Шәһәр Советы комиссиясенә (алга таба – Шәһәр Советы комиссиясе) тапшырыла.

8. Муниципаль вазифа биләүне дәгъвалаучы гражданин яисә муниципаль вазифа биләүче зат үзләре тапшырган мәгълүматларда нинди дә булса мәгълүматның чагылмавын яисә тулысынча чагылмавын ачыкласалар, алар әлеге Нигезнамәдә билгеләнгән тәртиптә төгәллек кертелгән мәгълүматлар тапшырырга хокуклы.

Муниципаль вазифа биләүче зат төгәллек кертелгән мәгълүматларны әлеге Нигезнамәнең 4 пунктында күрсәтелгән срок тәмамлангач бер ай эчендә тапшырырга мөмкин.

9. Муниципаль вазифа биләүне дәгъвалаучы гражданин яисә муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан әлеге Нигезнамә нигезендә тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү законнар нигезендә Шәһәр Советы Комиссиясе тарафыннан башкарыла.

10. Муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан объектив сәбәпләр буенча хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары хакында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар тапшырылмаган очракта, әлеге факт Керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту буенча Шәһәр Советы комиссиясе тарафыннан каралырга тиеш.

11. Муниципаль вазифа биләүне дәгъвалаучы гражданин яисә муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан әлеге Нигезнамә нигезендә тапшырылган мәгълүматлар конфиденциаль характрдагы мәгълүматлар булып тора, әгәр алар федераль законнар нигезендә дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматларга кертелмәсә.

Әлеге мәгълүматлар федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда вазифаи затларга күрсәтелергә мөмкин.

12. Муниципаль вазифа биләүче затның, аның хатынын (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында, шулай ук җир кишәрлеген, башка күчемсез милек обектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кагәзьләр (оешмаларның устав капиталларындагы катнашу өлеше, пайлары) сатып алу буенча килешү төзү өчен средстволар алу чыганаклары (әгәр мондый килешүләрнең суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) килешү төзер алдыннан килгән соңгы өч ел өчен гомуми кеременннән артып китсә) турында мәгълүматлары законнарда билгеләнгән тәртиптә «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырыла, бу

мәгълүматлар муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында булмаган очракта, массакүләм мәгълүмат чараларына аларның соратулары буенча бастыру өчен тапшырыла.

13. Муниципаль вазифа биләүне дәгъвалаучы гражданин яисә муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан әлеге Нигезнамә нигезендә тапшырылган мәгълүматлар белән эшләргә вәкаләтле, әлеге мәгълүматларны таратуда яки законнарда каралмаган максатларда куллануда гаепле, шулай ук дәүләт серен тәшкил иткән яисә конфиденциаль булган мәгълүматларны таркатуда гаепле затлар законнар нигезендә җаваплылыкка ия.

14. Муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан әлеге Нигезнамә нигезендә тапшырылган керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар, вазифа буенча вәкаләтләр бирелгәндә (вазифага билгеләнггәдә, сайланганда), шулай ук алар тарафыннан ел саен тапшырыла торган керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар һәм әлеге мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар муниципаль вазифаны биләүче затның шәхси эшенә теркәлә.

Әлеге Нигезнамә нигезендә керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәглүматларны тапшырган гражданин муниципаль вазифа буенча вәкаләтләр алмаган очракта, бу белешмәләр аның язма гаризасы нигезендә башка документлар белән бергә аңа кире кайтарыла.

15. Муниципаль вазифа биләүне дәгъвалаучы гражданин яисә муниципаль вазифа биләүче зат керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар бирмәгән яки күрәләтә ялган мәгълүматлар биргән очракта, законнар нигезендә җаваплылыкка ия.

Муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан үзенең чыгымнары хакында мәгълүматлар бирмәү яки тулы булмаган яки ялган мәгълүматлар бирү яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында мәгълүматлар бирмәү яки күрәләтә тулы булмаган яки ялган мәгълүматлар бирү, әгәр мондый мәгълүматларны бирү мәҗбүри булган очракта, биләгән вазифадан законнарда билгеләнгән тәртиптә азат итүгә китерүче хокук бозу булып санала.

Шәһәр Советының
7/17 нче Карарына 2 кушымта
7 апрель, 2016 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифа биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керенмәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларын шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны, бастырып чыгару өчен, массакүләм мәгълүмат чараларына бирү турында нигезнамә

1. Әлеге нигезнамә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифа биләүче затларның һәм аларның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) урнаштыру буенча бурычларны һәм әлеге мәгълүматларны, соратуларына бәйле рәвештә, бастырып чыгару өчен, массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен билгели, әгәр федераль законнар белән күрсәтелгән мәгълүматларны урнаштыруның һәм (яки) бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирүнең башка тәртибе билгеләнмәсә.

2. Муниципаль вазифаларны биләүче затларның керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында түбәндәге мәгълүматлары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлары рәсми сайтка урнаштырыла һәм, аларның соратуларына бәйле рәвештә, бастырып чыгару өчен, массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла:

1) муниципаль вазифа биләүче зат, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары милек хокукында ия булган яки файдалануда булган күчемсез мөлкәт исемлеге, төрен, мәйданын һәм мондый объектларның һәркайсының урнашкан илен күрсәтеп;

2) муниципаль вазифа биләүче зат, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары милек хокукында ия булган транспорт чаралары исемлеге, төрен һәм маркасын күрсәтеп;

3) муниципаль вазифа биләүче затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының игълан ителгән еллык кереме;

4) җир кишәрлеген, башка күчемсез милек обектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кагәзьләр (оешмаларның устав капиталларындагы катнашу өлеше, пайлары) сатып алу буенча килешү төзү өчен средстволар алу чыганаклары (әгәр мондый килешүләрнең суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) килешү төзер алдыннан килгән соңгы өч ел өчен гомуми кеременннән артып китсә) турында мәгълүматлар.

3. Рәсми сайтка урнаштырыла һәм бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла торган керемнәр,

чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларда түбәндәгеләрне күрсәтү тыела:

1) муниципаль вазифа биләүче затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәр хакында, милек хокукында ия булган мөлкәт һәм мәлкәти характердагы йөкләмәләр хакында башка мәгълүматларын (әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлардан тыш);

2) муниципаль вазифа биләүче зат хатынының (иренең), балаларының һәм башка гаилә әгъзаларының шәхси мәгълүматларын;

3) муниципаль вазифа биләүче зат хатынының (иренең), балаларының һәм башка гаилә әгъзаларының тору урынын, почта адресын, телефонын һәм башка шәхси коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматларны;

4) муниципаль вазифаны биләүче зат хатынының (иренең), балаларының һәм башка гаилә әгъзаларының милек хокукында ия булган яки аларда файдалануда булган күчемсез мөлкәт объектларының урнашкан урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматларны;

5) дәүләт серен тәшкил иткән яисә конфиденциаль булган мәгълүматны.

4. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар зат тарафыннан вазифалар биләүнең бөтен чорына (вазифаларны биләү аның керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларын, шулай ук аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәр хакында, милек хокукында ия булган мөлкәт һәм мәлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларының игълан ителүен таләп итә) хезмәткәр вазифа биләгән органның рәсми сайтында тора һәм ел саен, аларны тапшыру өчен билгеләнгән срок чыккан көннән алып 14 көн эчендә яңартыла.

5. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларны рәсми сайтка урнаштыру Хаким (Шәһәр Советы) аппараты тарафыннан тәэмин ителә:

1) массакүләм мәгълүмат чарасыннан сорату кергән көннән алып өч эш көне эчендә сорату кергән муниципаль вазифаны биләүче затка бу турыда хәбәр итәләр;

2) әгәр соратылган мәгълүмат рәсми сайтта булмаган очракта, массакүләм мәгълүмат чарасыннан сорату кергән көннән алып җиде эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны тапшыруны тәэмин итәләр.

6. Хаким (Шәһәр Советы) аппаратының керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларны рәсми сайтка урнаштыруны һәм аларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастыру өчен тапшыруны тәэмин итүче муниципаль хезмәткәре әлеге Тәртипне үтәмәгән өчен, шулай ук дәүләт серен тәшкил иткән яки конфиденциаль булган мәгълүматларны тараткан өчен, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка ия.